ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 523-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 523-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2402-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 3 пунктында «һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге объектларга инвестиция проектларын» сүзләрен «һәм башка инвестиция проектларын» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 өлештә «дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык, концессия килешүләре, сәнәгать сәясәте, махсус икътисадый зоналар һәм социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр турындагы законнарда каралган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

2024 елның 5 гыйнварыннан үз көченә кергән (аерым нигезләмәләрдән тыш) «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон белән үзгәрешләр, шул исәптән «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль законга да, кертелде.

Әлеге үзгәрешләр белән капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуының рәвешләре һәм алымнары, аерым алганда, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары исәбеннән финанслана торган инвестиция проектларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру, төгәлләштерелде.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына шундый ук үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституциясенә төзәтмәләр нигезендә закон проекты проектлана торган Татарстан Республикасы законнарының барлык текстында республиканың иң югары вазыйфаи заты исеменә үзгәрешләр кертүне күздә тота.

Шулай ук хокукый җайга салуны камилләштерү тәртибендә закон проекты белән Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуын башка рәвешләр һәм алымнар кулланып гамәлгә ашыру мөмкинлегенә карата Россия Федерациясе законнары нигезендә конкрет тармакларны күрсәтүне төшереп калдыру күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.